**Кич утырып укыгыз әле**

**Без бәләкәй чакларда**
**Кулланган күп сүзләрне**
**Белми хәзер балалар,**
**Югалтты мәгънәләрне.**

**Мич белән стена арасын**
**Кәбәрткә дия идек,**
**Элекке сәкеләр хәзерге**
**Тахта, диваннар кебек.**

**Мич башында да йокладык,**
**Җылы урынны көйләп,**
**Калай мичкә салам яктык,**
**Җылынсын диеп өйләр.**

**Уеннан өшеп кайткач,**
**Люкс булды сәндерә,**
**Кәбәрткәдән – мич башына**
**Кем җитез, шул өлгерә.**

**Кара мунча иде элек,**
**Төтен ишектән чыкты,**
**Төннек аша кергән һава**
**Җиләтте бит мунчаны.**

**Кәбәрткәдә – яшь бәрәннәр,**
**Бозау да шунда иде,**
**Ялгышмаска бәрәннәргә**
**Чүпрәкләр тага идек.**

**Бераз үскәч, бәрәннәрне**
**Сәке астына керттек,**
**Көнгә өч тапкыр аларны**
**Имезеп алып кердек.**

**Ә сыерны өйгә кертеп,**
**Саудылар иртә-кичен,**
**Сыерның “күчтәнәч”еннән**
**Саклангannнардыр ничек?**

**Сәке астында яз көне**
**Казлар бәбкә чыгарды,**
**Ярыгыннан күз ташласаң,**
**Чеметкәләп тә алды.**

**Коляскалар булмаган шул**
**Безне үстергән чакта,**
**Тирбәлеп үскәнбез без**
**Асылмалы бишектә.**

**Асып куйганнар талбишек**
**Сәке өстенә җайлап.**
**Матчага кадаклаганнар**
**Пружиналарын майлап.**

**Чаршау белән бүленгән**
**Булды йокы бүлмәсе.**
**Килен белән кияүне**
**Килде шунда күрәсе.**

**Чигүле башлы сөлгеләр**
**Элеп куйды киленнәр.**
**Бирнәләрен сандыкка**
**Алар салып килделәр.**

**Кизәк җыеп яктык дисәң,**
**Көлә хәзер балалар.**
**Тиресне ничек сукканны**
**Белми шул инде алар.**

**Күл буенда, яланаяк**
**Тиресне таптый идек,**
**Калыпларга тутырып,**
**Матурлап тезә идек.**

**Кояшта кипкәч аларны,**
**Вак өемнәргә тездек,**
**Бәләкәй арбага салып,**
**Тау итеп аннан өйдек.**

**Юллыкта каен утынны**
**Чырагачка киптердек,**
**Мичне һәм казан асларын**
**Чыра белән тергездек.**

**Кисәү агачы һәм соскы –**
**Мичнең көлен тартырга,**
**Җәмки дигән кыскыч булды**
**Утлы күмер тотарга.**

**Соскыга тутырып аны**
**Калай савытка салдык,**
**Ә суынгач, самоварга**
**Чәй кайнатырга алдык.**

**Шул күмерне саласың да**
**Самовар торбасына,**
**Өстенә чыра ташлыйсың,**
**Суы тиз кайнасынга.**

**Киштәдә саклана иде**

**Барлык булган әйберләр,**

**Стенка ролен үтәде ул,**

**Булмагач башка җирләр.**

**Онны иләп җилпучларга**

**Чоланнан алып кердек,**

**Күәс чиләгендә басып,**

**Аннан ипи пешердек.**

**Мичнең көлен җыеп алдык**

**Юеш пумала белән,**

**Ипине мичкә тезделәр**

**Агач көрәкләр белән.**

**Әнкәй алдан алыр өчен**

**Көлчә дә куя иде,**

**Өф-өф итеп, пешә-пешә**

**Май белән ашый идек.**

**Көянтә-чиләкләр белән**
**Елгадан су ташыдык.**
**Сиртмәле кое тоткасын**
**Әйләндереп су алдык.**

**Комган белән юындык,**
**Бер-беребезгә салып су,**
**Күз алдына да килмәде**
**Краннан аккан мондый су.**

**Түшәк – такта караватта,**
**Баш астында –зур ястык.**
**Сәкеләрдә тезелешеп**
**Барыбыз бергә яттык.**

**Мендәр тышлары чигүле,**
**Төрле-төрле зурлыкта,**
**Сандык өстенә тезеләр,**
**Урынны җыйган чакта.**

**Талдан үргән читән, киртә,**
**Утыртмалар – агачтан,**
**Өй түбәләре саламнан,**
**Кайберләре – камыштан.**

**Иген басуы читләре**
**Үр иде – хәйран биек,**
**Кул белән аны өйделәр**
**Кош-корт кермәсен диеп.**

**Мара уарга барганда**
**Куркытты безне атлар.**
**Сикереп чыкканда үрне,**
**Булды егылган чаклар!**

**Төрле төстәге ташларны**
**Кулда сикертә идек,**
**Төсле керәч ватыклары –**
**Әйбәт уенчык иде.**

**Урак тотып җыйган булдык**

**Бакчадагы чүпләрне,**

**Ә әниләр ашлык урып,**

**Шаккатырган күпләрне.**

**Ат кузгалаклары җыеп,**

**Алабута сыдырып,**

**Кош-кортларны ашаттык без**

**Тугым итеп болгатып.**

**Төсле чүпрәкләрне төреп**

**Курчаклар ясый идек.**

**Баудан сикергечләр ясап**

**Без төрлечә сикердек.**

**Ә малайлар җыелышып**

**Тачкалар ясадылар.**

**Ком-таш салып, хуҗалыкта**

**Ярдәм иттеләр алар.**

**Тыкырыкка буранлы кар**
**Ясый иде сырынты,**
**Өстеннән йөри алырлык**
**Була иде бик каты.**

**Кыш көне агач чанада**
**Сырынтыларда шудык.**
**Тактадан бөгеп ясалган**
**Чаңгыга чират тордык.**

**Уйнаганда бит очлары**
**Туңа иде кайчакта,**
**Каз мае белән әниләр**
**Уа иде шул чакта.**

**Тау буйлары гөрли иде,**
**Бала-чага туп-тулы,**
**Саф һавада уйнарга да**
**Вакыт табылып торды.**

**Туңмай белән сызык сызган**
**Бәрәңге боламыгы,**
**Умач уып пешергән аш**
**Ашарга тәмле булды.**

**Керосин салган лампага**
**Кидердек бишле куык,**
**Корымнарын чистартып**
**Куя идек көндез үк.**

**Онытылмый әле һаман**
**Сумала чәйнәгәннәр,**
**Кәнфит кәгазьләреннән дә,**
**Ясадык без чәчәкләр.**

**Куык ватылса әгәр дә,**
**Сукыр лампага калдык.**
**Сукыр лампа яктысында**
**Дәрес хәзерләп алдык.**

**Куыклы фонарь иде**

**Лапаска чыккан чакта,**

**Корымланды куыгы**

**Билтә күтәргән чакта.**

**Агач ручка белән яздык,**

**Каләм аңа кидердек,**

**Кара савытындагы карага**

**Манып без яза идек.**

**Магнитофон урынына**

**Патефон иде элек,**

**Таба куеп, әйләндереп,**

**Яратып тыңлый идек.**

**Кабага йонны бәйләп**

**Орчыкка җеп эрләдек,**

**Бишенәдә оекбашлар,**

**Бияләйләр бәйләдек.**

**Ярма ташында ярдык та**
**Пешердек бодай боткасын,**
**Менә шулай яра идек**
**Ярмаларның барысын.**

**Сөяк эчендәге җилек**
**Бик тәмле була иде,**
**Кашыкка кага-кага**
**Суырып ашый идек.**

**Ат арбасына утырып**
**Йөрдек сабантуйларга,**
**Шундый “таксилар” иде**
**Без бәләкәй чакларда.**

**Селте, катык белән юдык**
**Озын толым чәчләрне,**
**Зарланмадык, үстердек без**
**Берәү дә кистермәде.**

**Агач тарак иде элек**

**Чәчебезне тарарга,**

**Матур итеп үрә идек**

**Бантиклап, толымнарга.**

**Кер тактасында сыдырып,**

**Юдык барлык керләрне,**

**Селте белән кер сабыны –**

**Башка нәрсә белмәдек.**

**Күмер сала торган үтүк**

**Күргәнегез бармы соң?**

**Шуның белән үтүкләдек**

**Юган кернең барысын.**

**Утлы күмерләр салдык та**

**Уңга-сулга болгадык,**

**Үтүк кызгач, сүрелгәнче**

**Керләрне без барладык.**

**Язлар җиткәч яланнарда**
**Уйнап һич тә туймадык,**
**Сыер ябагасыннан да**
**Туплар ясап уйнадык.**

**Патефоннарга алмашка**
**Магнитофоннар чыкты,**
**Тасмаларын өзмәс өчен**
**Беребез карап торды.**

**“Орбит”, “Дерол” урынына**
**Сумала чәйнәп үстек.**
**Авыз эчләрендә аны**
**Шарт-шорт китерә идек.**

**Вак акчалар күп иде,**
**Бер тиен, ике тиен,**
**Санап бетермәле түгел,**
**Өч, ун һәм унбиш тиен.**

**Көз көне балалар чыкты**
**Колхоз басуларына,**
**Бәрәңгеләр чүпләделәр,**
**Сетка капчыкларына.**

**Буяу карандашы белән**
**Буядык кәгазьләрне,**
**Кулдан ясалган уенчык –**
**Матур бит элгәннәре.**

**Кәнфит кәгазьләреннән дә,**
**Чәчәкләр ясый идек,**
**Аларын да чыршы бизәп,**
**Бик матур итеп элдек.**

**Октябрят, пионерларны**
**Хәзер белмиләр инде,**
**Комсомол, коммунист та юк,**
**Яңа замана килде.**

**Эх, кайтасы иде дә соң**
**Кабат шул бала чакка,**
**Күпме генә теләсәк тә**
**Булмый шул барып артка.**

**Вакыт уза, яшь тә бара,**
**Булмый бер дә туктатып,**
**Җир шары тиз әйләнәдер,**
**Утырам мин шаккатып.**

**Искә төшә бала чаклар**
**Уйланып утырганда.**
**Бала чакка кайткан кебек**
**Китаплар укыганда.**

**Төшкә керә кайчакларда**
**Сөн буенда комлыклар.**
**Бакча артындагы тауда**
**Чанада шуган чаклар!**

**Картлык килеп ишек шакый,**
**Үтте яшьлек, балачак,**
**Матур мизгелләре аның**
**Күңелдә сакланачак.**

**Онытыла бик күп сүзләр,**
**Мәгънәсен дә белмиләр,**
**Сөйләсәң бала чакны,**
**Чак кычкырып көлмиләр.**

**Яздым әле искә алып,**
**Белсен диеп балалар,**
**Рәсемнәр карап булса да**
**Танышып алсын алар.**

**Балаларга истәлеккә**
**Калсыннар әле болар.**
**Искә алып сөйләгәндә**
**Гаҗәпләнмәсен алар.**

***(Бу шигырьнең авторы билгесез. Аны безгә авылдашыбыз Габдуллина Гүзәл Габделхак кызы 2024 елның ноябрендә җибәрде)***